**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районының**
**Арча шәһәр муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр**
**башкарма комитеты**

**422000, ТР, Арча ш., Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-15-25, 3-12-35**

**Муниципальное образование**
**город Арск**
**Арского муниципального района**
**Республики Татарстан**
**исполнительный комитет**
**города Арск**
**422000, РТ, г.Арск, площадь Советская, 27**
**тел. 3-15-25, 3-12-35**

# КАРАР

**«14» декабрь 2015 ел** **№ 211**

**Арча шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә Яңа ел бәйрәме чаралары чорында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү турында**

«Татарстан Республикасы территориясендә махсус янгынга каршы режим урнаштыру турында» 03.12.2015 ел, №913 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Яңа ел бәйрәме көннәрендә янгыннарны кисәтү һәм «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә кешеләр күпләп йөри торган урыннарда иминлекне тәэмин итү максатларында, Башкарма комитет КАРАР БИРӘ:

1. 2015 елның 15 декабреннән 2016 елның 10 гыйнварына кадәр Арча шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә пиротехника эшләнмәләрен куллану өчен түбәндәге мәйданчыкларны билгеләргә:

–ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Подгорная ур., 1а адресы буенча урнашкан стадион;

- «Балыкчы авылы» ЖЧЖнең автомобиль тукталышы янындагы территория;
- Арча шәһәренең Күл урамына таба уң якта урнашкан мәйданчык;
- Арча-Әтнә автомобиль юлының уң ягында урнашкан су башнясы каршындагы мәйдан;
- Айван авылындагы Арча-Төбәк-Чокырча автомобиль юлының уң ягында автобус тукталышыннан 100 м ераклыкта урнашкан мәйданчык;
- Магистраль һәм Үзәк урамнары киселешеннән 300 метр ераклыкта урнашкан мәйданчык;
- Күпербаш авылында Казансу елгасы аша күпердән 50 метр ераклыкта урнашкан мәйданчык.

2. Пиротехник эшләнмәләр куллану өчен махсус җиһазландырылган мәйданчыкларны кешеләр күпләп йөри торган объектларның (кибетләр, сәүдә үзәкләре һ. б.) мәгълүмат стендларына урнаштырырга:

- "Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләү турында" 03.12.2015 ел, № 913 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары;

- Арча шәһәре Башкарма комитетының әлеге карары;

- пиротехник эшләнмәләр кулланганда янгын куркынычсызлыгы чаралары буенча белешмәлек.

3. Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләү һәм «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә пиротехник эшләнмәләр куллану мәйданчыкларын билгеләү турында халыкка мәгълүмат бирүне оештырырга.

4. Яңа ел бәйрәмнәре чорына тәкъдим ителә:

4.1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләү турында» 2015 ел, 3 декабрь, 913 нче карарын, пиротехник эшләнмәләр кулланганда янгын куркынычсызлыгы чаралары буенча белешмәлекне гражданнарга җиткерергә.

4.2. «Жилкомбытсервис» ҖЧҖнә Арча шәһәре муниципаль берәмлеге торак пунктларында янгынга каршы тышкы су белән тәэмин итү чыганакларына илтә торган юлларны вакытында чистартырга;

4.3. Арча шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан авыл клублары мөдирләренә:

- Яңа ел бәйрәме чараларын уздыру чорында кизү торуны тәэмин итәргә;

- янгын сүндерү чараларының төзек торышын тәэмин итәргә;

- ведомство карамагындагы учреждениеләрдә урам чыршыларын бизәү өчен сертификацияләнгән электр гирляндларын кулланырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарлары К.В. Гомәровка, Р. Р. Шәмсетдиновка йөкләргә.

Арча шәһәре башкарма
комитеты җитәкчесе

Р. Ф. Касыймов